«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы

КАРАРЫ

2024 елның 28 августы № 109

«Җир салымы турында» 2017 елның 13 ноябрендәге 67 номерлы «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 387 статьясындагы 2 пункты, шулай ук «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 36 статьясы нигезендә КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы 2017 елның 13 ноябрендәге 67 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяның беренче өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- җирле үзидарә органнары, су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү объектлары, гомуми файдаланудагы мәйданнар, урамнар, юллар, парклар, аллеялар, яшел утыртмалар, истәлекләр, бәйрәм чараларын үткәрү урыннары, спорт объектлары һәм гомуми файдаланудагы башка объектлар биләгән җир кишәрлекләренә карата җирле бюджеттан финанслана торган бюджет, казна учреждениеләре.».

2. Әлеге карарның 3 статьясындагы 5 абзацы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз йогынтысын кертә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Кариле авылы, Пионер ур., 1;

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Чаллы авылы, Ленин ур., 43;

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кече Кариле авылы, Вахитов ур., 16, шулай ук Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

« Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Олы Кариле
авыл җирлеге » муниципаль берәмлек
башлыгы, Совет рәисе Ф.Г.Гарифуллин